Олы Елга авыл җирлеге башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2016 елның 06 октябре Олы Елга ав. № 25

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны кулланучыларда эшкәртелгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 8 пунктына, тиешле дәрәҗәдә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 3 сентябрендәге 681 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Олы Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны кулланучыларда беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеген расларга.

2. Кулланылган терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында мәгълүматны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Елга авылы, Октябрь ур., 25 йорт урнашкан стендта, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru рәсми сайтында, шулай ук эшкәртелгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннарына куярга.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы,Үзәк урамы, 9 йорт; Саескан Тауы авылы, Үзәк урамы, 16А йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

“Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ә.Садриев

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 06 октябрендә кабул ителгән 25 номерлы карары белән расланган.

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны кулланучыларда беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге**

1. Олы Елга ав. ( Октябрь ур. , 25 йорт).